**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3625**
**03.05.2023**

Башкарма комитетның 2013 елның 6 сентябрендәге 5433 номерлы карары белән расланган җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 6 сентябрендәге 5433 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 29 июнендәге 3353 номерлы, 2018 елның 6 сентябрендәге 4986 номерлы, 2019 елның 1 мартындагы 1105 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

- сигезенче абзацны төшереп калдырырга;
- унынчы абзацта «2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы» сүзләрен «2021 елның 8 апрелендәге 246-р номерлы» сүзләренә алмаштырырга;
- унберенче абзацта «Башкарма комитет Җиткчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы» сүзләрен «Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.3.1 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов